ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УСЫ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ ЖИТӘКЧЕСЕ
423739, Качкын авылы,
Үзәк ур.,37внче йорт
Тел.3-44-63.
e-mail: usin.akt@tatar.ru

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
РУКОВОДИТЕЛЬ ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО
КОМИТЕТА УСИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО МУНИ-
ЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
423739, деревня Качкиново,
ул.Центральная, дом 37в,
тел.3-44-63.
e-mail: usin.akt@tatar.ru

КАРАР

26 июнь 2026 ел №10

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Усы авыл җирлеге территориясендә беренчел хәрби исәпкә алуны оештыру һәм гамәлгә ашыру турындагы Нигезләмәне раслау хакында

«Оборона турында» 1996 елның 31 маендагы 61-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә мобилизацион әзерлек һәм мобилизация турында» 1997 елның 26 февралендәге 31-ФЗ номерлы, «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» 1998 елның 28 мартындагы 53-ФЗ номерлы Федераль законнары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 27 ноябрендәге "Хәрби исәпкә алу турындагы Нигезләмәне раслау турында" 719 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы "Усы авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставы белән, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Усы авыл җирлеге Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Усы авыл җирлеге территориясендә беренчел хәрби исәпкә алуны оештыру һәм гамәлгә ашыру турындагы Нигезләмәне расларга (1 нче кушымта).
2. Усы авыл җирлеге территориясендә гражданнарны беренчел хәрби исәпкә алу буенча җаваплы кешенең вазыйфаи инструкциясен расларга (2 нче кушымта).
3. Усы авыл җирлеге Башкарма комитетының «Усы авыл җирлеге территориясендә гражданнарны беренчел хәрби исәпкә алуны оештыру һәм гамәлгә ашыру турында" Нигезләмәне раслау хакында" 2019 елның 15 гыйнварындагы 1 номерлы карарын (2019 елның 19.06 № 14, 01.04.2020 ел № 9, 19.04.2021 ел № 6 кертелгән үзгәрешләр белән) үз көчен югалткан дип танырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.
5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Актаныш муниципаль районы
Усы авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе Э.И.Вазиева

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН АКТАНЫШСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ОГРН 1061682011104
р 06-3541/08
Исполнительный комитет Усинского сельского поселения
ИНН 1604007089

Татарстан Республикасы
Актаныш муниципаль районы Усы
авыл җирлеге Башкарма комитеты
26.06.2026г. №10 карарына 1 нче
кушымта

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Усы авыл җирлеге территориясендә беренчел хәрби исәпкә алуны оештыру һәм гамәлгә ашыру турында Нигезләмә

## 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1. Беренчел хәрби исәпкә алуны Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Усы авыл җирлеге (алга таба – җирлек) хәрби исәпкә алу хезмәткәре гамәлгә ашыра.

1.2. Хәрби исәпкә алу хезмәткәре үз эшчәнлегендә «Оборона турында» 1996 елның 31 маендагы 61-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә мобилизацион әзерлек һәм мобилизация турында» 1997 елның 26 февралендәге 31-ФЗ номерлы, «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» 1998 елның 28 мартындагы 53-ФЗ номерлы Федераль законнары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 27 ноябрендәге 719 номерлы «Хәрби исәпкә алу турындагы Нигезләмәне раслау турында»гы карары, Россия Оборона министрлыгы тарафыннан 2017 елның 11 июлендә расланган, җирле үзидарә органнарында беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру буенча методик тәкъдимнәр һәм Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары белән, Актаныш муниципаль районы «Усы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы белән, шулай ук әлеге Нигезләмә белән җитәкчелек итә.

1.3. Нигезләмә Актаныш муниципаль районы Усы авыл җирлеге Башкарма комитеты тарафыннан раслана.

## 2. ТӨП БУРЫЧЛАР

2.1. Хәрби исәпкә алуның төп бурычлары булып:

а) гражданнарның Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән хәрби бурычын үтәвен тәэмин итү;

б) хәрби исәптә торучы гражданнар турында хәрби исәпкә алу белешмәләрен документаль рәсмиләштерү;

в) мобилизациянең кеше ресурсларының сан составын һәм сыйфат халәтен анализлап, илнең оборонасы һәм дәүләт куркынычсызлыгы мәнфәгатьләре өчен аларны һөнәри файдалану;

г) мобилизация вакытында һәм хәрби вакытта Россия Федерациясенең Кораллы Көчләрен, башка гаскәрләрне, хәрби оешмаларны һәм органнарны тыныч тормыштан хәрби хезмәткә күчерү чараларын үткәрү өчен запаста торучы һәм хәрби хезмәткә җәлеп ителә торган гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләү өчен кирәкле санны планлы эшләп һәм тәэмин итү;

## 3. ФУНКЦИЯЛӘР

Беренчел хәрби исәпкә алу документларындагы белешмәләрне җыюны, саклауны һәм эшкәртүне оештыру һәм тәэмин итү максатларында җирле үзидарә органнары һәм аларның вазыйфаи затлары:

3.1. Үз территориясендә яшәүче яки вакытлыча (3 айдан артык) торучы, шул исәптә яшәү урыны һәм вакытлыча тору урынында теркәлмәгән гражданнарның, шул исәптә запаста булган һәм хәрби хезмәткә чакырылачак гражданнарның беренче хәрби исәбен алып бара;

3.2. Үз территориясендә яшәүче яки вакытлыча (3 айдан артык) торучы, шул исәптә яшәү урыны һәм вакытлыча тору урынында теркәлмәгән гражданнарны хәрби исәпкә куеп, эчке эшләр органнары белән берлектә ачыклый;

3.3. Үз территориясендә урнашкан оешмаларның исәбен алып бара һәм аларда хәрби исәп алып баруны контрольдә тота;

3.4. Беренчел хәрби исәпкә алу документларын машинкада һәм электрон төрләрдә Россия Федерациясе Оборона министрлыгы билгели торган тәртиптә һәм формалар буенча алып баралар һәм саклыйлар.

3.5. Беренчел хәрби исәпкә алу документларын тиешле хәрби комиссариатларның һәм оешмаларның хәрби исәпкә алу документлары белән елга кимендә 1 тапкыр чагыштыралар;

3.6. Беренче хәрби исәпнең документларында урнашкан мәгълүматларга үзгәрешләр кертә һәм 10 эш көне эчендә Россия Федерациясенең хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән форма буенча хәрби комиссариатларга кертелгән үзгәрешләр турында хәбәр итә;

3.7. Оешмаларның вазыйфаи затларына һәм гражданнарга аларның хәрби исәпкә алу, мобилизацион әзерлек һәм мобилизация буенча Россия Федерациясе законнарында һәм әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән бурычларын аңлаталар, аларның үтәлешен тикшереп торалар, шулай ук күрсәтелгән бурычларны үтәмәгән өчен җаваплылык турында хәбәр итәләр;

3.8. Оешмаларның вазыйфаи затлары һәм гражданнарның хәрби исәпкә алу, мобилизацион әзерлек һәм мобилизация бурычларын үтәмәү очраклары турында белешмәләрне алар ачыкланган көннән алып 10 эш көне эчендә электрон формада, шул исәптән мәгълүматны машинада алына торган саклагычта тапшыралар.;

3.9. Ел саен, 1 февральгә кадәр, тиешле хәрби комиссариатларга узган елда беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру нәтиҗәләре турында хисап тапшыралар.

## 4. ХОКУКЛАР

4.1. Планлы һәм максатчан эшләү өчен хәрби исәп буенча хезмәткәр хокуклы:

дәүләт хакимиятенең федераль органнарыннан, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, шулай ук оештыру-хокукый рәвешләренә һәм милек рәвешләренә бәйсез рәвештә учреждениеләрдән һәм оешмалардан кирәкле материалларны һәм мәгълүматны билгеләнгән тәртиптә соратып алу буенча тәкъдимнәр кертергә;

җирле үзидарә органы администрациясенең структур бүлекчәләреннән аналитик материалларны, чараларның гомуми планнары буенча тәкъдимнәрне һәм аларның үтәлеше турындагы мәгълүматны, шулай ук йөкләнгән бурычларын нәтиҗәле үтәү өчен кирәкле башка материалларны соратып алу;

үз компетенциясенә кергән мәсьәләләр буенча мәгълүматлар базасын төзү;

җирле үзидарә органы җитәкчесенә аерым эшләрне үтәү өчен килешү нигезендә хезмәткәрләрне җәлеп итү мәсьәләләрен карарга кертү;

билгеләнгән тәртиптә үзара хезмәттәшлекне оештырырга һәм федераль башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр, шулай ук оешмалар белән үз компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр буенча хезмәти язышуны тәэмин итү.

## 5. ИДАРА ИТҮ

5.1. Хәрби исәп буенча хезмәткәр Актаныш муниципаль районы Усы авыл җирлеге

Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан билгеләнә һәм вазыйфасыннан азат ителә һәм бер үк вакытта эшчәнлек алып бара.

5.2. Хәрби исәп буенча хезмәткәр турыдан-туры Актаныш муниципаль районының Усы авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесенә буйсына.

5.3. Җитди сәбәпләр аркасында (отпуск, вакытлыча эшкә яраксызлык, командировка) хәрби исәпкә алу буенча хезмәткәр эш урынында булмаган очракта, аны Актаныш муниципаль районы Усы авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе алмаштыра.

Татарстан Республикасы
Актаныш муниципаль районы Усы авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе 26.06.2026ел №10 карарына
2 нче кушымта

Усы авыл җирлеге территориясендә гражданнарны беренчел хәрби исәпкә алуны алып бару буенча җаваплы затның вазыйфаи бурычлары

Усы авыл җирлеге территориясендә гражданнарның беренчел хәрби исәбен алып бару буенча җаваплы вазыйфаи зат булып тора һәм авыл җирлеге башлыгына буйсына.

Усы авыл җирлеге территориясендә гражданнарны беренчел хәрби исәпкә алуны алып бару буенча җаваплы зат үз эшендә Россия Федерациясе Конституциясенә, гамәлдәге федераль законнарга һәм Татарстан Республикасы законнарына, РФ Хөкүмәтенең норматив хокукый актларына таяна.

Беренчел хәрби исәпкә алуны алып бару буенча җаваплы зат җирлектә беренчел хәрби исәпкә алуны оештыру һәм гамәлгә ашыру өчен җаваплы була.

Беренчел хәрби исәпкә алуны алып бару буенча җаваплы зат Усы авыл җирлеге Башкарма комитетына йөкләнгән бурычлар нигезендә:

1) җирлек территориясендә яшәүче яисә торучы (өч айдан артык вакытка) запаста булган гражданнарны һәм хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле гражданнарны беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашырырга;

2) җирлек территориясендә яшәүче яисә булган (өч айдан артык вакытка) хәрби исәптә торырга тиешле гражданнарны эчке эшләр органнары белән берлектә ачыкларга;

3) авылда урнашкан оешмаларның исәбен тоту һәм аларда хәрби исәпнең алып барылуын күзәтү;

4) Россия Федерациясенең оборона министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм формада беренче хәрби исәп документларын алып бару һәм саклау;

5) Актаныш районы хәрби комиссариатының документлары белән елына кимендә бер тапкыр беренчел хәрби исәпкә алу документларын чагыштырырга;

6) беренчел хәрби исәпкә алу документларындагы белешмәләргә үз вакытында үзгәрешләр кертәләр һәм 10 эш көне эчендә хәрби комиссариатларга кертелгән үзгәрешләр турында Россия Федерациясе Оборона министрлыгы билгели торган форма буенча хәбәр итәләр;

7) оешмаларның вазыйфаи затларына һәм гражданнарга аларның Россия Федерациясе законнарында һәм хәрби исәп буенча Нигезләмәдә билгеләнгән хәрби исәпкә алу, мобилизацион әзерлек һәм мобилизация буенча бурычларын аңлатырга һәм аларның үтәлешен тикшереп торырга, шулай ук күрсәтелгән бурычларны үтәмәгән өчен җаваплылык турында хәбәр итәргә;

8) гражданнарның хәрби исәпкә алу, мобилизацион әзерлек һәм мобилизация бурычларын үтәмәү очраклары турында белешмәләрне алар ачыклангannan соң 10 эш көне эчендә электрон формада, шул исәптән алына торган машина мәгълүмат чыганагында Актаныш районы хәрби комиссариатына тапшырырга;

9) хәрби билетларның (хәрби билетлар урынына бирелгән вакытлыча таныклыкларның) яисә хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле гражданнар таныклыкларының булу-булмавын һәм дөреслеген, шулай ук алардагы язмаларның дөреслеген, мобилизация күрсәтмәләренең (хәрби билетларда аларны тапшыру турында тамгалар булганда запастагы хәрби бурычлыларга), гражданнарны хәрби билеттан төшерү турында хәрби исәпкә алу документларындагы тамгаларның булуын тикшерергә, Россия

Федерациясе гражданнарының хәрби бурычка мөнәсәбәте турындагы паспортларындагы тамгаларны элеккеге яшәү урыны буенча исәпкә алу;

10) тутырырга:

- запастагы офицерларның беренчел исәп карточкалары;

- прапорщикларга, мичманнарга, старшиналарга, сержантларга, солдатларга һәм запастагы матросларга алфавит карточкалары һәм исәп карточкалары (ике экз.);

- чакырылучыларның беренчел хәрби исәп карталары.

11) хәрби исәпкә алынган гражданннарның документларында булган гаилә хәле, белеме, эш урыны, вазыйфасы, яшәү урыны яки булу урыны турында кирәкле мәгълүматларны ачыклау;

12) чакырылучыларны хәрби исәпкә кую өчен Актаныш районының хәрби комиссариатына шәхси килеп күренүнең кирәклелеге турында хәбәр иту;

13) хәрби исәп документларында һәм гражданнарның мобилизация күрсәтмәләрендә табылган төзәтмәләр, төгәлсезлекләр, ялган кәгазьләр һәм кәгазьләрнең тулы булмаган саны турында Актаныш районы хәрби комиссариатына хәбәр итәргә;

14) Актаныш районы хәрби комиссариатына ике атна эчендә җирлектән читтә яңа яшәү урынына хәрби исәптән төшерелмичә киткән гражданнар исемлеген төзергә һәм тапшырырга;

15) хәрби исәптән төшерелгән гражданнарның беренчел хәрби исәпкә алу документларын Актаныш районы хәрби комиссариатының исәп белешмәләре белән чираттагы чагыштыруга кадәр сакларга, аннары аларны билгеләнгән тәртиптә юк итәргә.

16) ел саен, 1 февральгә кадәр, Актаныш районы хәрби комиссариатына алдагы елда беренчел хәрби исәпкә алу нәтиҗәләре турында хисап тапшырырга.